Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Манзарас авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

2022 елның 11 ноябре № 42

Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Өлге авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2022 елның 26 ноябрenә 10 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Өлге авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Өлге авылы, Үзәк урам, 19 йорт адресы буенча урнашкан авыл Мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

2. 2022 елның 26 ноябрenә 18 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Өлге авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Өлге авылы, Үзәк урам, 19 йорт адресы буенча урнашкан авыл Мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләр исемлеген аеруны (территориаль, вакытлы яки башка төрле билге буенча) сайлау тәртибе муниципаль берәмлек башлыгының гражданнар җыенын билгеләү турындагы карарында күрсәтелә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Манзарас авыл җирлегенең Өлге авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 1 төркем инвалидларыннан; 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдән һәм ялгыз аналардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Өлге авылында урам юл челтәрен карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү), проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Өлге авылына урам яктырту өчен энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Өлге авылы территориясен төзекләндерү;
- Өлге авылы юлларына асфальт җәю, торбалар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне тормышка ашыру, экспертиза үткәрү;
- Өлге авылы зиратын коймалау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Өлге авылының балалар мәйданчыгын коймалау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Өлге авылында су белән тәэмин итү системаларын төзү һәм ремонтлау (торбаларны алыштыру, материал, җиһазлар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү), проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Физкультура һәм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, спорт чараларын уздыруны оештыру: булган яссылык спорт корылмаларын карап тоту, тренировкалар оештыру, спорт чараларын әзерләү һәм уздыру өчен белгеч тоту;
- Су башняларын буяу өчен буяулар сатып алу, су башняларын буяу, су башняларын ремонтлау, насослар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Манзарас авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Хәбибуллина